# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ
# К А Р А Р

19.11.2018 № 218

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә 2018 елның 19 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында участок комиссияләренең беренче нөсхәләре мәгълүматлары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе 2018 елның 19 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзегән, аның нигезендә, 2018 елның 19 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 345 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны-285, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның 82,61% ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 276 (96,84%) кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 9 кеше тавыш бирде, бу 3,16 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә **2018 елның 19 ноябрендәге җирле референдум** узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип таныргa.
2. "2019 елда, Яңасала авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш) үзара салым акчасын җыярга һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Яңасала авылы Үзәк урамда 18 нче йорттан алып 49 йортка кадәр, Мәктәп урамында 1 нче йорттан алып 7 нче йортка кадәр, юл урам читтәренә вак таш җәю

2. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

Каенсар авылындагы су башнясы өчен насос сатып алу.

3. Җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

Яңасала, Каенсар авылында (һәр торак пунктта берешәр) янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә" дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителде дип танырга.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева